СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

11.11.2024г. | с. Майдан | № 51-264

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең торак пункты территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Мәйдан җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Мәйдан авылының торак пунктының бер өлешенең халык төркеме инициативасын карап.

Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2024 елның 22 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылы җирлеге Мәйдан авылы торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Мәйдан авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Мәйдан авылы территориясе өлешендә гражданнар җыенын түбәндәге урамнарда уздырырга:

Яшьләр урамы, 1 нче йорт янында - 9.00 сәгатьтә,

4. Мәйдан авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев